ГОСУДАРСТВЕННАЯ
ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Б.Красная, д.15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ
ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ
Б.Красная ур., д.15/9, Казан шәһәре, 420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

ПРИКАЗ № 412 БОЕРЫК

«10» 07 2015г.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә гражданнардан һәм оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибе турында

2003 елның 12 маендагы “Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында” 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясы нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымта булып килүче Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә (алга таба – ТР ДТИ) гражданнардан һәм оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибен расларга.

2. Гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлегенә (Т.В, Зайцева) елга ике тапкыр, яртыеллыкның соңгы аеннан соң килүче айның 15 көненә кадәр гражданнардан һәм оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ (алга таба – анализ) ясарга.

3. Җыелма анализ һәм автоматлаштыру бүлегенә (И.С. Начвин) анализны яртыеллыкның соңгы аеннан соң килүче айның 15 көненнән соңга калмыйча ТР ДТИ рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны башлык урынбасары И.И. Шәйдуллинга йөкләргә.

Башлык С.А.Крайнов

Татарстан Республикасы
Дәүләт торак
инспекциясенең 2015
елның 10.07.
412 номерлы
боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә гражданнардан һәм оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибе

1. Әлеге Тәртип 2003 елның 12 маендагы "Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында" 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә (алга таба – ТР ДТИ) гражданнардан һәм оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләрне (алга таба – мөрәҗәгатьләр) гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау электрон документ әйләнеше белешмәләре, әлеге Тәртипнең 3 һәм 4 пунктлары нигезендә тапшырыла торган мәгълүмат, шулай ук "Дәүләт капиталь ремонт программасын формалаштыру һәм аның үтәлешен мониторинглау һәм торак фонды объектларының торышын мониторинглау буенча дәүләт мәгълүмат системасы"нда билгеләнгән хисап тоту рәвешләрендә җыелма анализ һәм автоматлаштыру бүлеге (алга таба – ҖАА бүлеге) тарафыннан тапшырыла торган мәгълүмат нигезендә гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге (алга таба – Бүлек) тарафыннан башкарыла.

3. Башлык, башлык урынбасары (алга таба – ТР ДТИ җитәкчелеге, гражданнарны кабул итү буенча вәкаләт бирелгән затлар) тарафыннан шәхси кабул итү барышында килгән мөрәҗәгатьләр турындагы мәгълүмат гражданнарны ТР ДТИ җитәкчелегенә шәхси кабул итү өчен теркәп баручы белгеч тарафыннан Бүлеккә тапшырыла.

4. Урынга чыгып кабул итүләр турындагы мәгълүмат Бүлеккә гражданнарны кабул итү буенча вәкаләт бирелгән затлар тарафыннан тапшырыла.

5. Анализ үткәргәндә килгән, бер урыннан икенче урынга җибәрелгән һәм карап тикшерелгән язмача мөрәҗәгатьләрнең, электрон документ әйләнеше рәвешендәге мөрәҗәгатьләрнең саны, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре турында, шәхси кабул итү барышында кабул ителгән гражданнарның саны турында, гражданнарны кабул итү буенча вәкаләт бирелгән затлар һәм урынга чыгып шәхси кабул итү турында, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы турында, мөрәҗәгатьләрне карап тикшерү нәтиҗәсендә кабул ителгән чаралар, шул исәптән кабул ителгән норматив-

хокукый һәм башка төрле актлар (булган очракта) турында мәгълүмат өйрәнелә.

6. Әлеге Пунктның 2, 3 һәм 4 пунктларында күрсәтелгән мәгълүмат Бүлеккә җаваплы хезмәткәрләр тарафыннан яртыеллыкның соңгы аеннан соң килүче айның 5 көненә кадәр тапшырыла.

7. Бүлек башлыгы 2 пунктта күрсәтелгән, шулай ук әлеге Тәртипнең 3 һәм 4 пунктлары нигезендә килгән мәгълүматларны килгән көненнән алып ике эш көне дәвамында гомумиләштерә һәм анализлый һәм анализны ТР ДТИ башлыгының тикшереп торучы урынбасары белән килештерә.

8. Мөрәҗәгатьләрнең анализы ҖАА бүлегенә ТР ДТИ рәсми сайтында урнаштыру өчен җибәрелә. Анализ ТР ДТИ рәсми сайтында яртыеллыкның соңгы аеннан соң килүче айның 15 көненнән соңга калмыйча урнаштырыла.

9. ТР ДТИ килгән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә ясалган анализ ТР ДТИ рәсми сайтында (http://gji.tatarstan.ru) ирекле файдаланудагы ачык мәгълүмат булып санала.

КИЛЕШТЕРЕЛДЕ:

ТР ДТИ башлыгы урынбасары Ф.М. Низамов

Юридик бүлек башлыгы А.А. Хәмидуллин

Гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән
эшләү бүлеге башлыгы Т.В. Зайцева